ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МУСАБАЙ-ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

«03» апрель 2024 ел Таш-Кичу авылы № 6

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге составына керүче Таш-Кичу авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 октябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 27 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Таш-Кичу авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Таш-Кичу авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Мусабай-Завод авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Советының 2019 елның 08 ноябрендәге 49/2 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге составына керүче Таш-Кичу авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 октябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 27 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Таш-Кичу авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апреленә 13.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге составына керүче Таш-Кичу авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 октябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тезү, ремонтлау, карап тоту (юл өслегенең юл өлеше астына су үткәрү торбасын өлешчә алмаштыру һәм куаклардан, агачлардан чистарту (махсус техника));

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам утларын ремонтлау)».

2) 1 пунктның икенче-өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 27 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Таш-Кичу авылында гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тезү, ремонтлау, карап тоту (юл өслегенең юл өлеше астына су үткәрү торбасын өлешчә алмаштыру һәм куаклардан, агачлардан чистарту (махсус техника));

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам утларын ремонтлау)».

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Мусабай-Завод авыл җирлеге, Таш-Кичу авылы, Озерный ур., 3В йорт ( Мәдәният йорты).

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Мусабай-Завод авыл җирлеге Башлыгы З.З. Хесәинова

Исполнительный комитет Мусабай-Заводского сельского поселения
ИНН 1639032216
ОГРН 1061682004394